ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

02.04.2018 | № 18

д. им. М. Вахитова

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту буенча икеайлык үткәрү турында

Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен оештыру һәм аларны экологик куркынычсызлыкка туры китерү өчен, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2018 нче елның 30 нчы мартында кабул ителгән 316 нчы номерлы Карарын үтәү максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2018 нче елның 1 нче апреленнән 31 нче маена кадәр Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту буенча икеайлык (алга таба – икеайлык) игълан итергә.

2. Вахитов авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составын расларга (№1 кушымта).

3. Вахитов авыл җирлегенең 2018 елга торак пунктларын төзекләндерү буенча чаралар планын расларга (2 нче кушымта).

4. Вахитов авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләренә, милек формасына карамастан, якын-тирә территорияләрне төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен оештырырга тәкъдим итәргә. Урыннарда агач һәм куаклар утырту, биналарның фасадларын ремонтлау эшләрен оештырырга.

5. Авыл җирлеге территориясендә күчемсез милеккә ия булган гражданнарга, нинди хокукка ия булуга карамастан, үзләренең йорт яны территорияләрен санитар чистарту буенча эш алып барырга тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Вахитов авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Вахитов авыл җирлеге башлыгы М.К. Идиятуллин

Вахитов авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2018 елның
2 апрелендәге 18 номерлы карарына
1 нче кушымта

Вахитов авыл җирлегенең төзекләндерү комитеты составы

1. Идиятуллин Марат Каюм улы-Вахитов авыл җирлеге башлыгы
2. Фәйзулова Асия Лотфулла кызы-Бакча-Сарай авыл клубы мөдире
3. Сафина Фәния Галиәхмәт кызы-Вахитов авыл мәдәният йорты мөдире
4. Миңнуллин Рамил Зөфәр улы-1 номерлы Вахитов сайлау округы депутаты

5. Бәйрәмова Рузалия Гайнелҗан кызы- 4 номерлы Ташевка сайлау округы депутаты

Вахитов авыл җирлеге башлыгы М.К. Идиятуллин

Вахитов авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2018 елның
2 апрелендәге 18 номерлы карарына
2 нче кушымта

Вахитов авыл җирлегенең 2018 елга торак пунктларын төзекләндерү буенча чаралар ПЛАНЫ

| № | Чара исеме | Үткәрү датасы | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Санкцияләнмәгән чүплекләрне ачыкларга (Торак пунктлар территорияләрендә, урманнарда, утыртмаларда, юл буе полосаларында, елга, инеш һәм чокыр ярларында, кешеләр ял итә торган урыннарда) чүп-чар чыгаруны оештырырга | даими | Авыл җирлеге башлыгы, авыл җирлеге Советы депутатлары, учреждение җитәкчеләре |
| 2 | Авыл җирлеге территориясендә чүплекләрне бетерү буенча эшләрне оештырырга һәм үткәрергә | апрель-май | Авыл җирлеге башлыгы, авыл җирлеге Советы депутатлары, учреждение җитәкчеләре |
| 3 | Авыл җирлеге территориясендә Казан-Шеланга трассасы буенда чүп-чар җыю һәм баганаларны агарту | апрель - май | Авыл җирлеге башкарма комитеты, учреждение җитәкчеләре |
| 4 | Мәктәп укучыларының урман культуралары, агачлар, куаклар утырту эшен оештырырга | май | Авыл җирлеге башкарма комитеты, мәктәп директорлары |
| 5 | Вахитов  авылы мәчете территориясен төзекләндерү. | май | Авыл җирлеге Советы депутатлары, халык |
| 6 | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны төзекләндерү (коймаларны ремонтлау, коймаларны буяу, чүп-чар чыгару) | май | Авыл җирлеге Советы депутатлары, халык |
| 7 | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан учреждениеләр, предприятиеләр биналарының фасадларын ремонтлау | аперель-май | Предприятие, учреждение җитәкчеләре |
| 8 | Йорт фасадларын, коймаларны, шәхси сектор коймаларын ремонтлау | апрель-май месяцы | Авыл җирлеге Советы депутатлары, халык |
| 9 | Поселок эчендәге юлларны грейдерлау | апрель-май | Авыл җирлеге башлыгы, предприятие җитәкчеләре |
| 10 | Авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы территориясен төзекләндерү | май | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 11 | Авыл җирлегендә чишмәләрне төзекләндерү | май | Авыл җирлеге Советы депутатлары, халык |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 12 | "Татарстанның чиста урманнары» һәм " Урман утырту көне” акцияләрендә катнашырга | даими | Авыл җирлеге башлыгы, авыл җирлеге Советы депутатлары, учреждение җитәкчеләре |
| 13 | Авыл җирлегендә санитар-экологик хәлне яхшырту буенча мәктәп укучыларын конкрет эшкә җәлеп итү | даими | Мәктәп директорлары |

Вахитов авыл җирлеге башлыгы М.К. Идиятуллин